**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Иске Мавринавыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**13.11.2023ел** **№ 112**

**Зәй муниципаль районы Иске Маврин**
**авыл җирлеге Советының**
**2013 елның 25 ноябрендәге 108 номерлы**
**«Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл**
**җирлегендә бюджет процессы турында**
**Нигезләмәне раслаутурында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

2019 елның 26 июлендәге 199-ФЗ номерлы «Дәүләт (муниципаль) финанс контролен, эчке финанс контролен һәм эчке финанс аудитын камилләштерү өлешендә Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль законга, 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы«Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы законнарына,2023 елның 9 мартындагы 16-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм “Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында”гы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына, Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советы

карар итте:

Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлеге Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 108 нче номерлы карары (10.03.2015 №154.2, 28.05.2018 №106, 12.11.2019 №168, 21.07.2021 №37, 21.06.2022 №70 карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә расланган Зәй муниципаль районы Иске Маврин авыл җирлегендә бюджет процессы нигезләмәсенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 8 нче пунктындагы 50 нче абзацынтүбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет дефицитын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне планлаштыруны (фаразлауны) гамәлгә ашыра (бюджетның бердәм счетындагы акча калдыкларын идарә итү операцияләреннән, бердәм

салым түләүенә бәйле операцияләрдән, мәҗбүри түләүләргә карата Евразия икътисади берлеге хокукы һәм Россия Федерациясе законнары белән каралган аванс түләүгә бәйле операцияләрдән, Евразия икътисади берлеге хокукы һәм Россия Федерациясенең таможня көйләве турындагы законнары белән каралганакчалата залог белән бәйле операцияләрдән тыш );»;

1.2. 3 нче абзацның 17 нче пунктындагы 2 нче пунктчада «Татарстан Республикасы Президенты "сүзен “Татарстан Республикасы башлыгы (Раисе)" сүзләре белән алыштырырга;

1.3. 13 нче абзацның 35 нче пунктында «җирлекнең башкарма комитеты "дигән сүзләрне “районның финанс-бюджет палатасы "(төзелгән Килешү нигезендә) дигән сүзләр белән алыштырырга;

1.4. 37 нче пунктның 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2.Бюджет үтәлеше турындагы еллык хисап белән бер үк вакытта аңа бюдже т үтәлешенә һәм бюджет хисаплылыгына анализ ясалган аңлатма язуы, дәүләт (муниципаль)биременең үтәлеше һәм (яисә) бюджет ассигнован иеләреннән файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр,бюджет үтәлешенең закон(карар) проекты, тиешле бюджетның үтәлеше турында һәм тиешле консолидацияләнгән бюджетның үтәлеше турында бюджет хисабы, Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган башка документлар тапшырыла

2.Әлеге карарны “ Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында " бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), торак пунктлар территориясендә махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.Г. Нургалеев**